РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.05.2019 № 69-п

Саба муниципаль районы территориясендә табигый характердагы гадәттән тыш хәл аркасында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә китерелгән зыянны бәяләү буенча комиссия төзү турында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә көзге авыл хуҗалыгы культураларының һәлак булуына китергән тискәре табигый факторлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән азык-төлек иминлегенә куркыныч янауны булдырмау максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Саба муниципаль районы территориясендә табигый характердагы гадәттән тыш хәл аркасында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә китерелгән зыянны бәяләү буенча район комиссиясен кушымта нигезендә төзергә.

2. Районның авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә зыян күләмен һәм авария-торгызу эшләрен үткәрүгә чыгымнарын билгеләү өчен комиссия эшен оештырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Саба муниципаль районы башлыгы урынбасары Р. Р. Закирҗановка йөкләргә.

Р.Н. Минниханов

РАСЛАНДЫ
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башлыгының
06.05.2019 ел №69-п карары белән

**Саба муниципаль районы территориясендә табигый характердагы гадәттән тыш хәл аркасында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә китерелгән зыянны бәяләү буенча комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Закирҗанов Р.Р. | Саба муниципаль районы башлыгы урынбасары, комиссия рәисе; |
| Хуҗина Ә.А. | «Саба муниципаль районы буенча гражданнар оборонасы идарәсе» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе, комиссия секретаре (килешү буенча); |
| Члены комиссии: | |
| Ишниязов М.Р. | Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; |
| Хәсәншин Г.Ш. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Саба муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Мусина Ә.Җ. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Саба муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең финанс-икътисад бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| Нигамәтҗанов Р.Ф. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Саба муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге консультанты (килешү буенча); |
| Сафин Р.И. | Дәүләт статистикасы бүлегенең Алабуга шәһәрендә (Байлар Сабасы штб) әйдәп баручы белгече (килешү буенча); |
| Кәбиров В.С. | «Россельхозцентр» ФДБУнең Татарстан Республикасы буенча филиалының Саба районара бүлеге башлыгы (килешү буенча). |